| | |
|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| 25.02.2021 | № 04-05-24 |

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2018 нче елның 29 нчы июнендә язылган 09-05-102 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында,

2020 нче елның 27 нче октябрендә 346-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 22 нче һәм 48 нче маддәләренә үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны кабул итү, Россия Федерациясе Президентының 2020 нче елның 6 нчы октябрендә 616 номерлы “Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” Указ чыгаруы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 нче елның 24 нче сентябрендә 1546 номерлы “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына үзгәрешләр кертү турында” карар чыгаруына бәйле рәвештә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2018 нче елның 29 нчы июнендә язылган 09-05-102 номерлы “Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәне раслау турында” боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы

вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.4. Конкурс комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе һәм (яисә) аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге эшләрен алып бару һәм структур бүлекчәсе өчен җаваплы хезмәткәре), Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – Дәүләт комитеты рәисенең бәйсез белгечләрнең шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә чакырылучы кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча тиешле өлкәләрдә һәм һөнәри хезмәт эшчәнлегенең төрләрендә белгечләр булган фәнни, белем бирү һәм башка оешма вәкилләре керә.

Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Бу бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына яңадан кертү аның конкурс комиссиясендә тору вакыты беткәч өч елдан сон гына башкарылырга мөмкин.

Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

Дәүләт комитеты рәисе соравы буенча конкурс комиссиясе составына кертелүче Дәүләт комитеты карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, Дәүләт Комитеты карамагындагы тиешле Иҗтимагый совет карары нигезендә билгеләнәләр”.

3.4 нче пунктның “г” пунктчасының икенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

“нотариус яисә хезмәт итү (эш) урынында кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш)”;

3.4 нче пунктның “г” пунктчасының өченче абзацында “эш (хезмәт итү) урыны буенча” сүзләрен “хезмәт итү (эш) урыны” сүзләре белән алыштырырга;

4.4.12 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“Конкурс комиссиясе үзенең әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме буенча видеоконференция форматында (техник яктан мөмкинлек булса) утырыш үткәрергә карар кабул итә ала, бу карарның сәбәбен (нигезен) күрсәтә.

Дәүләт комитеты тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатларның конкурс процедураларын узуы өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла”.

4.4.13 нче пунктны түбәндәгечә тулыландырырга:

“4.4.13 Кандидатның йомгаклау баллы конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләгән индивидуаль әңгәмә, башка конкурс биремнәре нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары кандидатка биргән уртача арифметик баллар һәм кандидат тарафыннан тест нәтиҗәләре һәм нәтиҗәләрне формальләштерелгән исәпләүне тәэмин итүче башка охшаш конкурс биремнәре үтәлеше нигезендә тупланган баллар суммасы буларак исәпләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләренә нигезләнеп, конкурс комиссиясе секретаре йомгаклау баллары тәртибендә кандидатларның рейтингын формалаштыра”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Председатель вазыйфаларын башкаручы И.Г. Багаутдинов